Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XLIII-7**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 26 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу хакында Нигезләмәне раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы “Татарстан Республикасы милке турындагы мәгълүматны ачу хакында Нигезләмәне раслау турында” 327 номерлы Карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә инвестицион активлыкны үстерү, шулай ук үзидарәлек милкен тагын да нәтиҗәлерәк һәм рациональ файдалану максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу хакында Нигезләмәне расларга (теркәлә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы Рәисе Вафин Ф.М.ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2019 елның
26 июнендәге XLIII-7 номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу хакында Нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу хакында Нигезләмә 2006 елның 27 июлендәге "Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр турында һәм мәгълүматны саклау хакында" 149-ФЗ номерлы, 2001 елның 21 декабрендәге "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 178-ФЗ номерлы, 1993 елның 21 июлендәге "Дәүләт сере турында" 5485-1 номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасының 2005 елның 8 апрелендәге "Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында" 65-ЗРТ номерлы Законы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан ачыла торган Балык Бистәсе муниципаль районы үзидарәлек милке турындагы мәгълүмат составын, шулай ук аны, шул исәптән милекнең аерым объектлары буенча да ачу ысулларын, тәртибен һәм срокларын тәгаенли.

1.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу дигәннән барлык кызыксынучы затларның аңа керү мөмкинлеген тәэмин итү аңлашыла.

1.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милкен исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан бирелә. Мәгълүматны бирүдә кире кагу соратыла торган мәгълүматта дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларның булу очрагында мөмкин.

1.4. Юридик затлар буенча бирелгән мәгълүматны алар мәнфәгатьләренә зыян китерүдә файдалану Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында күздә тотылган җаваплылылыкка сәбәп була.

1.5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке Реестрында теркәлгән мәгълүматлар күләмендә, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының мәгълүмат базасындагы җир кишәрлекләре турында мәгълүматлар күләмендә бирелә.

1.6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке турында мәгълүматны ачу мәгълүмат тарату һәм кызыксынучы затларга мәгълүмат бирү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Мәгълүматны тарату мәгълүматны гаммәви мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм "Интернет" челтәрендәге сайтта урнаштыру аркылы гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат бирү кызыксынучы затларның язма мөрәҗәгатьләре буенча, шул исәптән милекнең аерым объектлары буенча гамәлгә ашырыла.

## 2. Мәгълүмат тарату

2.1. "Интернет" челтәрендәге сайтта урнаштыру аша таратыла торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке турында мәгълүмат түбәндәге (керү мөмкинлеге закон белән чикләнелгән мәгълүматларны эченә алган очраклардан гайре) мәгълүматлар исемлеге белән билгеләнә:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы үзидарәлек учреждениеләре исемлеге (исеме, урнашу урыны);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы үзидарәлек унитар предприятиеләре исемлеге (исеме, урнашу урыны);

устав капиталы өлешләре (акцияләр пакетлары) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге (хуҗалык җәмгыятенең исеме, урнашу урыны, устав капиталында үзидарәлек өлеше);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендә булган күчемсез мөлкәт (йортлар, биналар) исемлеге (исеме, урнашу урыны, мәйданы, максатчан билгеләнеше, файдалануны чикләү, өченче затларның хокуклары белән комачаулау);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы үзидарәлек мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы үзидарәлек мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) үтәү турында хисап.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке турында күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук гаммәви мәгълүмат чараларында игълан ителергә (бастырылырга) мөмкин.

2.2. Әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар ел саен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында 1 гыйнварга булган торыш буенча финанс елы тәгәлләнгәннән соң дүрт айдан да соңга калмыйча игълан ителергә тиеш.

2.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милкендәге объектлары турында мәгълүматны аларны хосусыйлаштыру сәбәпле ачу хосусыйлаштыру турындагы закон белән билгеләнгән күләмдә гамәлгә ашырыла.

3. Кызыксынучы затларга мәгълүмат бирү

3.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке Реестрында теркәлгән мөлкәтнең аерым объектлары буенча мәгълүмат (алга таба – исәпкә алу объектлары) кызыксынучы затларның мөрәҗәгате буенча хат яки Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке Реестрыннан өземтә рәвешендә бирелә.

3.2. Исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат (яки аны бирүне кире кагу турында дәлилле карар) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан мөрәҗәгатьне теркәү көненнән соң 30 көннән артмаган срокта бирелә.

3.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке Реестрыннан өземтәләр бирелә:

исәпкә алу объектларының хокукый ияләренә яки аларның законлы вәкилләренә;

исәпкә алу объектларының хокукый ияләреннән яки аларның законлы вәкилләреннән ышанычнамә алган физик һәм юридик затларга;

Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының Хисап палаталарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Контроль-хисап палатасына;

Татарстан Республикасының, Россия Федерациясенең башка субъектлары җирле үзидарә органнарына һәм дәүләт хакимияте органнарына;

Дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, шул исәптән:

күчемсез милеккә хокукларга һәм алар белән килешүләргә дәүләт теркәвен гамәлгә ашыручы органнарга,

салым органнарына,

исәпкә алу объектлары һәм (яки) аларның хокукый ияләре белән бәйле эшләре производствода булган судларга, хокук саклау органнарына, суд приставлары-башкаручыларына,

федераль монополиягә каршы органга һәм аның Татарстан Республикасындагы территориаль органына.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында күрсәтелмәгән кызыксынучы затларга исәпкә алу объектларының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке Реестрында булуы турында гына мәгълүмат бирелә.

3.5. Сорала торган мәгълүматны бирүне кире кагу турында язма рәвештәге җавап дәлилләнгән булырга тиеш.

Сорала торган мәгълүматны бирүне кире кагуга нигез булып түбәндәге сәбәпләр тора:

мөрәҗәгатьтә керү мөмкинлеге закон белән чикләнелгән мәгълүматлар соралганда;

әлеге затны мәгълүматы кызыксындыра торган объектны мөрәҗәгатьнең эчтәлеге бер төрле генә таныкларга (тәңгәлләштерергә) мөмкинлек бирмәгәндә;

мөрәҗәгатьтә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль милке Реестрында мәгълүматы булмаган мөлкәт объекты күрсәтелгәндә.